***Тема: Арча районында туып үскән куренекле шәхесләр иҗаты аша сыйфат, аның дәрәҗәләре темасын кабатлау. ( интеграль дәрес)***

**Максат:**

1) сыйфат сүз төркеме турында белемнәрне тирәнәйтү, гомумиләштерү;
2) алган белемнәрне куллану күнекмәләре үстерү;
3) якташ язучыларыбызның иҗаты белән кызыксыну уяту, балаларда әхлак сыйфатлары тәрбияләү.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:** Сүз төркеме буларак, сыйфатларны таный, куллана белү. Төрле дәрәҗәдәге сыйфатларны аеру.

**Дәреснең тибы:** Белем һәм күнекмәләрне комплексլы куллану дәресе.

**Төп төшенчәләр:** Сыйфат, мөстәкыйль сүз төркеме, дәрәҗә, гади, чагыштыру, артыклык, кимлек.

**Предметара бәйләнеш:** Әдәбият, инглиз теле.

**Эшне оештыру төрләре:** Фронталь, индивидуаль, парлап эшләү, төркемнәрдә эшләү.

**Чыганаклар: төп:** дәреслек;

**өстәмә:** слайдлар, карточкалар, күнегүләр җыентыгы, аудиоязма.

**Дәрес планы**

**I. Оештыру, мотивлаштыру.**

1) Исәнләшү.Уңай психологик халәт тудыру.
2) Арча гимнын тыңлау.

Бөек Тукай Ватаны, син, Арча!
Мөхәммәтләр Ватаны, син, Арча!
Ай- йолдызлар Ватаны син Арча!
Ватанымның ал таңы, син, Арча!

Җидегән чишмәләрдән ургылган моң,
Яшьлегеңә, кыйбла ача!
Мәрҗәнилар, Курсавилар рухы,
Гыйлем тавы булып алга баса.

- Димәк без сезнең белән әле генә нәрсә белән таныштык?Гимн, Арча гимны)
- Җырның сүзләренә игътибар итик, бу сүзләрнең гимн белән нинди бәйләнеше бар? ( шигырь юлларында безнең якташ, күренекле шәхесләребез турында сүз бара).

Бу дөньяда бер-береңне белеп-танып яшәүгә ни җитә? Туганнар, дуслар гына түгел, якташлар да чит җирләргә киткәч, бер-берсен эзләп таба. Әйтик, Казанда авылдашыңны, райондашыңны очрату ул туганың белән очрашуга тиң. Инде республикадан читкә китсәң, Татарстан кешесе синең өчен якынга әйләнә.Якташыбыз ( Ильфат Фәйзрахманов ( Түбән Оры) та туган ягыбыз турында шундый фикерләрен белдергән.

**II Дәрескә максат һәм бурычлар кую. Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.**

Әйе, бүген без сезнең белән якташ язучыларыбыз иҗатына күзәтү ясарбыз.

Ә хәзер тактага игътибар юнәлтик.

Урманында кып –кызыл кура җиләк тә җир җиләк;
Күз ачып йомганчы һичшиксез, җыярсың бер чиләк.
Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр
Берлә бергә үсә аллы –гөлле гөлләр, гөнҗәләр.
Ак, кызыл, ал, сап – сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр.
Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр.

*( Г.Тукайның “ Шүрәле” поэмасыннан өзек белән танышу).*

**III Белем һәм осталыкларны яңа ситуациядә куллану.**

**Текст буенча эш.**

1) Шигырь юлларын башта күңелдән, аннары 1 укучыдан сәнгатьле итеп укыту.

   Укучылар, билгеләнгән сүзләргә игътибар юнәлтик, үткән теманы да кабатлап китәрбез.

**а) сорауларга җаваплар бирү**

- Әлеге сүзләр башка сүз төркемнәреннән нәрсә белән аерылып тора?
- Бу сүзләр нинди сорауларга җавап бирә?

-Димәк сыйфатлар телебездә ни өчен кирәк? ( нәтиҗә)

( Сыйфатлар затның яисә предметның төрле билгеләрен белдерәләр.
Җиләк – кып –кызыл, нарат – төз һәм башкалар.
Антоним, синоним сыйфатлар була. Әйдәгез тексттагы сыйфатларның антонимнарын , синонимнарын табыйк.

**б) Антоним, синоним сыйфатларны билгеләү.** Нәтиҗә ясау.

( кайбер сүзләрнең антоним, синонимын билгеләп булмый).

Арча ягы рәссамнарының “ Көз” темасына иҗат иткән картиналары белән танышу.” Туган ягыбыз табигате” темасына картинаны тасвирлату. Сыйфатларны кулланып җөмләләр төзү.
( нәтиҗә)
**Ял итү минуты**

**Матур язу өстендә эш**.(Сыйфат кергән 2 җөмләне сайлап алып, күчереп язу).
Тип-тигез, киң асфальт юл. Бертуктаусыз машиналар, автобуслар үтеп тора. Ә юлның ике ягында алмагачлар. Алмагачлар яшь әле, бәләкәй әле. Әмма шундый көр булып, нык булып үсеп киләләр. Көз аларның яфрагын яки күлмәген төрле төскә бизәгән. Тукта, әнә теге алмагачта алма да бар түгелме? Әйе, кып-кызыл, түп-түгәрәк алма. Арырак әнә тагын бер алмагачта алма күренә, әйтерсең үзенә дәшә. *(Р.Төхвәтуллиннан)*
**в) төрле дәрәҗәләргә куеп карау** ( нәтиҗә чыгару: сыйфатлар 4 төрле дәрәҗәдә килә ала.Гади, артыклык, чагыштыру һәм кимлек.

**IV Ныгыту**
Алда башкарылган эшкә карап сыйфатның моделен төзеп карау :

**сыйфат**

| | | | |
|---|---|---|---|
| | нинди ? | исемне | җөмләдә |
| предметның | кайсы ? | ачыклый | аергыч, |
| билгесен | кайдагы ? | | хәбәр була |
| белдерә | | | |

Моделебезгә нәрсәләр җитми ? Дәреслектәге кагыйдәне уку.
Көтелгән җавап :
-Сыйфатланмыш турында әйтмәдек. ( нәтиҗә )

**V. Өй эше турында мәгълүмат, аны үтәү буенча күрсәтмә бирү.**
Өй эше турында мәгълүмат, аны үтәү буенча күрсәтмә бирү.
Өй эше:
а) модель буенча сыйфат турында сөйли белергә өйрәнергә;
б) иҗади эш: “Көзге табигать”турында сыйфатлар кертеп кечкенә күләмле хикәя язарга.
**VI. Рефлексия (дәрескә йомгак ясау).**
1.-Дәрескә нинди уку мәсьәләсе куйган идек ? Нәрсәләр эшләдек ? Нәрсәгә ирештек?

2.Дәрескә гомуми бәя кую.